ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**23.10.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2068**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Халык алдында сервитут билгеләү турында» 2019 елның 18 ноябрендәге 2467 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Техник хата җибәрелүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Халык алдында сервитут билгеләү турында» 2019 елның 18 декабрендәге 2467 номерлы карарына үзгәреш кертергә, аның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге 431-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Җир кодексының 23нче ст. таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә инженерлык инфраструктурасының линия объектларын һәм "Каты көнкүреш калдыкларын термик зарарсызландыру заводы" объектына керү юлларын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын раслау турында" 2019 елның 05 декабрендәге 1010 номерлы карарын исәпкә алып»

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы — А.В. Старостин